# КАРАР

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Лебедино авыл җирлеге составына керүче Лебедино авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

10 ноябрь 2019 ел. № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2019 елның 10 ноябрендә «2020 елда Лебедино авыл җирлеге территориясендә даими яшәүче һәр балигъ булмаган кешедән, 1 нче төркем инвалидлардан, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына чакырылган гражданнардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле мәсәләләрне хәл итүгә :

- җирлек эчендәге юлларга вак таш җәю,төзекләндерү һәм караптоту;
- техниканы карап тоту (тракторлар,УАЗ автомашиналары, янгын сүндерү автомашиналары, килешү буенча хезмәт хакы);
- авыл җирлегендә урамнарны яктырту һәм килешү буенча хезмәт хакы түләү;
-җирлек территориясен төзекләндерү (балалар мәйданчыгы территориясен койма белән әйләндереп алу һәм Бөек Ватан сугышында һәлак булучыларга һәйкәл кую өчен төзелеш материаллары сатып алу, агач кисү, триммер сатып алу, килешү буенча хезмәт өчен түләү).

ӘЙЕ ЮК

тоту белән килешәсезме? " мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре нигезендә беркетмә төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 341 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 191 кеше .

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 190 кеше тавыш бирде;
«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1.Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Лебедино авыл җирлеге составына керүче Лебедино авылындагы гражданнар җыены нәтиҗәләрен-вәкаләтле дип танырга.

2.“ 2020 елда Лебедино авыл җирлеге территориясендә даими яшәүче һәр балигъ булмаган кешедән, 1 Төркем инвалидларыннан, көндезге бүлектә укучы блеге студентлардан, Россия Армиясе сафларына чакырылган

гражданнардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле мәсәләләрне хәл итүгә :

- җирлек эчендәге юлларга вак таш җәю,төзекләндерү һәм караптоту;

- техниканы карап тоту (тракторлар,УАЗ автомашиналары, янгын сүндерү автомашиналары, килешү буенча хезмәт хакы);

- авыл җирлегендә урамнарны яктырту һәм килешү буенча хезмәт хакы түләү;

-җирлек территориясен төзекләндерү (балалар мәйданчыгы территориясен койма белән әйләндереп алу һәм Бөек Ватан сугышында һәлак булучыларга һәйкәл кую өчен төзелеш материаллары сатып алу, агач кисү, триммер сатып алу, килешү буенча хезмәт өчен түләү).

ӘЙЕ ЮК

тоту белән килешәсезме? " мәсьәләсе буенча карар кабул ителгән дип санарга.

3.Әлеге карарны Лебедино авыл җирлегенең рәсми сайтында, хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук Лебедино авылы, Кооператив урамы, 3, Лебедино авылы, Кооператив урамы, 3А, Лебедино авылы, Совет урамы, 65А адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

**Гражданнар җыенында рәислек итүче,**
**Лебедино авыл җирлеге башлыгы** **Ю.И. Тюкарев**